Татарстан Республикасы Әлмәт муниципаль районы
Ямаши авыл җирлегенең Ямаши авылында
гражданнар җыены нәтиҗәләре турында
КАРАР

22 ноябрь 2019 ел № 1

2003 елның 6 октябрендәге «Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» 131-ФЗ номерлы Федераль законның 25.1, 56 статьялары, 2004 елның 28 июлендәге «Татарстан Республикасында җирле үзидарә турында» Татарстан Республикасы Законының 35 статьясы, Татарстан Республикасы Әлмәт муниципаль районы Ямаши авыл җирлеге Уставының 13.1 статьясы, «Татарстан Республикасы Әлмәт муниципаль районы Ямаши авыл җирлегенең Ямаши авылында гражданнар җыенының беренче, икенче, этаплары тавыш бирү нәтиҗәләре (нәтиҗәләре) турында» 2019 елның 21 ноябрендәге беркетмәсе, Татарстан Республикасы Әлмәт муниципаль районы Ямаши авыл җирлегенең Ямаши авылында гражданнар җыены карар бирә:

1. Татарстан Республикасы Әлмәт муниципаль районы Ямаши авыл җирлегенең Ямаши авылында. узган халык җыенын үткәрелгән дип танырга, җыенның нәтиҗәләре - дөрес.

2. «Сез 2020 елда Татарстан Республикасы Әлмәт муниципаль районының Ямаши авыл җирлегенең Ямаши авылы территориясендә яшәү урыны буенча теркәлгән һәр балигъ булган яшәүчедән 500 сум (биш йөз) күләмендә үзара салым кертүгә һәм әлеге средстволарны җирле әһәмияткә ия мәсьәләләрне хәл итү өчен түбәндәге эшләрне башкару өчен җибәрү белән килешәсезме: торак пункт юлларын норматив хәлгә китерүгә?»

мәсьәләсе буенча карарны кабул ителгән дип танырга.

3. Халык җыены нәтиҗәләрен «Альметьевский вестник» газетасында, Ямаши авылы, Совет урамы, 4 дурт йорт территориясендә урнашкан махсус мәгълүмат стендында бастырырга, «Татарстан Республикасы хокукый мәгълүматлар рәсми порталында» (PRAVO.TATARSTAN.RU) һәм Әлмәт муниципаль районы сайтында урнаштырырга.

Халык җыенында рәислек итүче
Ямаши
авыл җирлеге башлыгы А.А. Андревкина